КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 20 декабрь г.Казань № 1177

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален үткәрү турында» 2016 ел, 9 июнь, 386 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален үткәрү турында» 2016 ел, 9 июнь, 386 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 14 июнь, 485 нче; 2018 ел, 24 август, 697 нче; 2019 ел, 19 апрель, 309 нчы һәм 2019 ел, 15 май, 394 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлар җәмгыяте, Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясе (төбәк эш бирүчеләр берләшмәсе), Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәдәниятне үстерүгә ярдәм күрсәтү фонды, югары белем бирүче «Казан дәүләт мәдәният институты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе, «Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм оешмалары яшьләре берлеге» төбәк иҗтимагый оешмасы, «Артиас» иҗади хезмәткәрләр берләшмәсе» Казан шәһәр

җәмәгать оешмасы, «Созвездие-Йолдызлык» Татарстан Республикасы төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы белән берлектә, «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален үткәрү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.»;

4 нче пунктның икенче абзацында «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционерлар җәмгыятенә» сүзләрен «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлар җәмгыятенә» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивале турындагы нигезләмәнең 1.3 нче пунктында «булып тормаган» сүзләрен «булып торган» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составында:

оештыру комитеты составыннан А.Р.Зариповны чыгарырга;

оештыру комитеты составына түбәндәгеләрне кертергә:

югары белем бирүче «Казан дәүләт мәдәният институты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры вазыйфаларын башкаручы Роза Шәйхәйдәр кызы Әхмәдиеваны (килешү буенча);

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәетгәрәй улы Сәлимгәрәевны;

Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасары Илдар Разин улы Фатыйховны;

Илшат Юныс улы Әминовның вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлар җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)»;

Владислав Викторович Майоровның вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм оешмалары яшьләре берлеге» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы директоры (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин